# ДУСЛАРЫМ КҮГӘРЧЕННӘРЕМ

Гөлдер гөлдер күгәрченнәр түбәләргә җыелган.
Сөенешеп гөрләшәләр язгы кояш нурында,
Сөенешеп гөрләшәләр язгы кояш нурында

Җимнәр сибеп сыйлыйм әле мин дә якын дусларны.
Исән имин чыктыгызмы, дуслар, салкын кышларны?
Исән имин чыктыгызмы, дуслар, салкын кышларны?

Күгәрченнәр шулчак килеп куналар учларыма.
Яратуым бүләк итәм шул нәни дусларыма.
Яратуым бүләк итәм шул нәни дусларыма.